
Редьярд Киплинг
Маугли
ТАТАРСТАН
КИТАП
НӘШРИЯТЫ

УДК 821.111-34-93
ББК 84(0)
К11

Рәссамы *Алсу Тимергалина*

Киплинг, Р. Дж.

К11 Маугли : балалар өчен әкият / Р. Дж. Киплинг ; [тәрҗ. Разил Вәлиев ; рәссамы Алсу Тимергалина]. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2015. — 96 б. : рәс. б-н.

ISBN 978-5-298-02837-0

УДК 821.111-34-93
ББК 84(0)

Литературно-художественное издание

Для детей среднего школьного возраста

Киплинг Редьярд Джозеф

МАУГЛИ

Казань. Татарское книжное издательство. 2015
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен

Киплинг Редьярд Джозеф

МАУГЛИ

Мөхәррире *Т. Р. Шакирова*. Бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*. Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *А. С. Газизҗанова*. Корректоры *Г. М. Хәбибуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 22.07.2015. Форматы 70×84 1/16.
Шартлы басма табагы 6,54. Тиражы 2500 д. Заказ

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
http://tatkniga.ru e-mail: info@tatkniga.ru

Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:

Казан, Декабристлар урамы, 2. Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге.
Тел.: (843) 519-45-35.
Казан, Бауман урамы, 29/11. Татарстан китап нәшриятының фирма кибете.
Тел.: (843) 292-03-18.
Казан, Декабристлар урамы, 2. Татарстан китап нәшриятының күргәзмә-кибете.
Тел.: (843) 519-45-13.

«Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

ISBN 978-5-298-02837-0

© Татарстан китап нәшрияты, 2015
© Вәлиев Р. И., тәрҗ., 2015

Мауглилар гаиләсе

Ата Бүре*, көндез бераз черем итеп алгач, йокы качырыр өчен киерелеп-сузылып, кашынып, оеган аякларын бер-бер артлы турайткалап куйганда, Сионий таулары өстенә чекллә киче иңгән һәм сәгать җиде тулган иде. Ана Бүре дәү башын дүрт баласы өстенә куеп йокымсырап ята, ә тегеләре кыймылдашалар, чинашалар. Алар гаиләсе яшәгән мәгарә авызына ай яктысы төшкән.

— Уф! — диде Ата Бүре. — Тагын аугa чыгарга кирәк.

Ул таудан түбән таба чабарга торганда, кинәт бусагага йонлач койрык шәүләсе төште һәм шыңшыган аваз ишетелде:

— Уңышлар телим сиңа, Бүреләр Башлыгы! Үзеңә уңышлар, затлы балаларыңа нык һәм сөттәй ак тешләр телим. Дөньяда ачлар да барын онытмасын балаларың!

Бу — шакал, Ялагай Табаки иде. Һиндстан бүреләре, теләсә кайда тыкшынып, коткы таратып, чүплекләрдә казынып йөргәне өчен, Табакины күралмыйлар. Үзләре Табакидан куркалар да, чөнки ул котыру авыруы белән джунглида барыннан да ешрак авырый һәм андый чакта урман буйлап шашынып чаба, юлда очраган берсен тешләми калмый.

* Сүзләрнең язылышы (баш һәм юл хәрефләре) чыганак телдәгечә бирелде.

Котырганда, нәни Табакидан хәтта юлбарыс та куркып кача, чөнки кыргый җәнлек өчен котырудан да куркынычрак чир юк. Алар бу авыруны «дивани», ягъни «диваналык» дип атыйлар һәм аннан бары качып кына котылып була дип уйлыйлар.

— Алайса, кер дә үзең кара, — дип, коры гына дәште Ата Бүре. — Тик ашар әйбер юк бездә.

— Бүрегә юк, — диде Табаки, — ә миндәй мескеннәргә коры сөяк тә — бәйрәм мәҗлесе. Без, шакаллар, алай назланып тормыйбыз.

Ул тавышсыз-тынсыз гына мәгарә түренә узды, яланып бетмәгән болан сөяге табып, бик канәгать кыяфәт белән җайлап утырды да аны шатыр-шотыр кимерә башлады.

— Сыегыз өчен рәхмәт! — диде ул, ялана-ялана. — Нинди матур бу затлы нәсел балалары! Күзләре томрап тора! Юкса үзләре кеп-кечкенә бит әле! Әй лә, патша балаларының тугандა ук зур булып тууларын истән чыгарганмын.

Балаларын әти-әниләрнең күзләренә карап мактаудан да яманрак нәрсә юклыгын бик яхшы белә иде Табаки, шуңа да Ана Бүре белән Ата Бүренең тынычсызлануларын ул ләззәтләнеп күзәтте.

Табаки, бүреләрне борчылырга мәҗбүр итә алуына сөенеп, тын гына утырды да мәкер белән әйтеп куйды:

— Шер-Хан, Олуг Юлбарыс, ау урынын алыштырды. Ул ауга монда киләчәк, ай буе тауларда булачак. Үзе шулай дип әйтте.

Шер-Хан мәгарәдән егерме миль* чамасы читтә, Вайңаңа елгасы буенда яшәүче юлбарыс иде.

---

* *Миль* — озынлык үлчәү берәмлеге. 1 миль 1,609 км га тигез.

— Аның хакы юк! — дип, усал гына сүз башлады Ата Бүре. — Джунгли Кануны буенча, беркемне дә кисәтми торып, ау урынын алыштырырга аның хакы юк. Ул тирә-юньдәге кош-кортларны моннан ун миль ераклыкка качырып бетерәчәк, ә миңа... миңа хәзер икебез өчен дә ауга йөрергә кирәк.

— Әни аны юкка гына Лаңри (Аксак) дип атамаган, — диде Ана Бүре тыныч тавыш белән. — Тумыштан ук бер аягы аксак аның. Шуңа күрә йорт хайваннарын гына аулый да ул. Вайнганга елгасы буенда яшәүчеләрнең аңа үче бар. Ул монда килгәч, бездә дә шундый ук хәлләр башланачак: кешеләр, урман тутырып, аны эзләячәк. Тота алмасалар, үләнгә ут төртәчәкләр. Шунда инде безгә, балаларыбызны ияртеп, дүрт якны кыйбла итеп качып китүдән башка чара калмаячак. Шер-Ханга «рәхмәт»ебез бик зур безнең!

— Сезнең «рәхмәт»не аңа җиткерергә мөмкинме? — дип сорады Табаки.

— Ычкын моннан! — дип теш шыгырдатты Ата Бүре. — Ычкын! Хуҗаң янына тай! Дөньяны болгатып та карадың инде.

— Китәм, — дип, тыныч кына җавап бирде Табаки. — Астан, чытырманлыктан, Шер-Хан тавышы тиздән сезгә дә ишетелер. Юкка гына китердем мин сезгә бу хәбәрне, юкка тырыштым.

Ата Бүре колакларын шомрайтты: инеш буендагы үзәндә юлбарысның усал һәм сагышлы үкерүе ишетелде. Ул бернәрсә дә аулый алмаган һәм бу турыда бөтен джунглига сөрән салудан тартынмый иде.

— Юләр! — диде Ата Бүре. — Төнге ауны шундый

шау-шу белән башлыйлармыни?! Безнең боланнарны Вайнңадагы симез буйволлар дип уйлый микәнни ул?

— Буйвол да, болан да ауламый ул хәзер, — диде Ана Бүре. — Кеше аулый ул.

Үкерү тонык ырылдауга әйләнде. Берьюлы бөтен яктан да ишетелгән бу ырылдау, ачык һавада төн үткәргән урман кисүчеләрнең һәм чегәннәрнең котын алып, кайчакта туптуры юлбарыс авызына таба йөгерергә мәҗбүр итә.

— Кеше аулый! — диде Ата Бүре, ак тешләрен ыржайтып. — Буада бакалар, коңгызлар беткәнме әллә? Кеше итенә кызыга ул, җитмәсә әле, безнең җирдә!

Джунгли Кануны кеше аулауны катгый тыя. Әгәр дә кешеләр үз балаларын усаллыкка, үтерешкә өйрәтсәләр, анысы — башка эш... Ләкин әле андый очракта да үз тупламы яисә ыруы ауга йөргән җирдә кеше үтерү тыела. Кешегә тисәң, филләргә атланган ак тәнле мылтыклы адәмнәрнең һәм кулларына гонглар, ракеталар, утлар тоткан йөзләгән кара тәнлеләрнең урманга киләсен көт тә тор. Менә андый чакта джунглида яшәүчеләрнең берсенең дә хәле шәптән булмас. Җәнлекләр кешене дөньяда иң зәгыйфь, иң яклаучысыз җан иясе диләр бит, һәм аны кыерсыту аучы өчен хурлык санала. Кеше ашаучыларның тешләре тиз бозыла һәм коелып бетә, дип тә дөрес әйтәләр.

Ырылдау авазы һаман көчәя барды, һәм кинәт күк күкрәгәндәй булды: «А-а-а!». Аннары юлбарыс корбаны өстенә ташланырга әзерләнеп тын калды.

Бераздан юлбарыс тавышына охшамаган улау — Шер-Хан улавы ишетелде.

— Тота алмады, — диде Ана Бүре. — Нишләп икән?

Ата Бүре мәгарәдән читкә йөгерде һәм куаклар арасында бөтерелүче Шер-Ханның ачулы ырылдавын ишетте.

— Бу юләр тәпиләрен пешергән. Утын кисүче учагына сикермәсә, акыллы диярләр иде! — дип пырхылдап куйды Ата Бүре. — Табаки да аның белән.

— Кемдер тауга менә, — диде Ана Бүре, бер колагын селкетеп. — Әзер тор.

Чытырманлык куаклары әкрен генә кыштырдап куйды, һәм Ата Бүре, сикерергә әзерләнеп, арткы тәпиләренә чүгәләде.

— Кеше! — дип ырылдады ул. — Кеше баласы! Кара әле!

Нәкъ алар каршында, аскы ботакка тотынып, әле яңа гына йөрергә өйрәнгән каратут тәнле шәрә бала — йоп-йомшак, кеп-кечкенә җан иясе басып тора иде. Мондый нәни баланың бервакытта да төнлә бүре өненә килгәне юк иде әле. Ул Ата Бүренең күзләренә карады да көлеп җибәрде.

— Кеше баласы шушындый буламыни? — дип сорады Ана Бүре. — Минем әле аны күргәнем юк иде. Алып кил әле монда.

Үз нәниләрен авызында йөртеп өйрәнгән Бүренең тешләре баланың җилкәсенә батып керсә дә, аны бәләкәй бүреләр арасына илтеп салгач, тиресендә аз гына тырналган эз дә калмады. Кирәк чакта Бүре күкәйне дә, ватмыйча, тешләре белән тотып тора ала.

— Нинди бәләкәй! Бөтенләй шәп-шәрә, ә үзе нинди кыю! — диде Ана Бүре, ягымлы гына итеп. (Бала нәни бүреләр арасыннан җылырак җиргә таба елышты.) — Ой! Ул да бүтәннәр белән бергә имә! Менә нинди икән ул кеше баласы! Моңа кадәр кайсы бүренең нәниләре арасында кеше баласының да яшәгәне бар әле?!

— Мондый хәл турында ишеткәнем бар иде, ләкин моның безнең Тупламда да, минем гомердә дә булганы юк, — диде Ата Бүре. — Ул бит шәп-шәрә, бер бөртек йоны да юк, аны бер сугуда үтерергә була. Күрсәнә, исе дә китмичә, безгә карап тора!

Кинәт мәгарәдә ай яктысы сүнде: Шер-Хан шакмак сыман зур башы белән тишекне томалады. Аның артында Табакиның чинаганы ишетелде:

— Әфәндем, әфәндем, ул шунда керде!

— Шер-Хан галиҗәнапларын күрү безгә дә насыйп икән, — диде Ата Бүре, әмма аның күзләре усал ялтырап куйды. — Шер-Ханга ни кирәк?

— Табышым кирәк! Монда кеше баласы керде, — диде Шер-Хан. — Аның әти-әнисе качып китте. Бирегез аны миңа.

Шер-Хан, чыннан да, утын кисүче учагына сикереп, тәпиләрен пешергән һәм хәзер шуңа усалланган иде. Әмма Ата